ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАНРЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 26.03.2021** **№ 317**

# Биектау муниципаль районы идарәсенең гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче органын билгеләү турында

1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында», 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы «Гражданнар оборонасы турында» һәм 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законнарны гамәлгә ашыру максатларында, Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Биектау муниципаль районы Гражданнар яклавы идарәсе» муниципаль казна учреждениесен Биектау муниципаль районы идарәсенең гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче органы итеп билгеләргә.

2. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче орган турында Нигезләмәне расларга.

3. «Биектау муниципаль районы Гражданлык яклавы идарәсе» муниципаль казна учреждениесе җитәкчесе И.Ю. Недоводинага билгеләнгән тәртиптә гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрүне планлаштыру һәм оештыру документларын эшләргә һәм килештерергә.

4. Биектау янгын-коткару гарнизоны начальнигы А.Ф Кәлимуллинга гражданнар оборонасы өлкәсендә документлар эшләүдә «Биектау муниципаль районы Гражданлык яклавы идарәсе» муниципаль казна учреждениесенә методик һәм гамәли ярдәм күрсәтүне тәкъдим итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru/ һәм Интернет челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында: http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф.Шәйдуллин

Расланган
Татарстан Республикасы
Биектау муниципаль районы
башкарма комитетының 2021
елның 26 мартындагы 317
карары белән

**Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче орган турында Нигезләмә**

## I. Гомуми нигезләмәләр

1. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче орган турында Нигезләмә (алга таба - Нигезләмә) Биектау муниципаль районы территориясендә халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче орган эшчәнлеген оештыруның төп бурычларын, функцияләрен, нигезләрен билгели.

2. Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау һәм гражданнар оборонасы өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә махсус вәкаләтле даими эшләүче орган (алга таба - даими эшләүче орган) үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ номерлы «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау турында» Федераль законга, 1994 елның 21 декабрендәге 69-ФЗ номерлы «Янгын куркынычсызлыгы турында» Федераль законга, 1995 елның 22 августындагы 151-ФЗ номерлы «Авария-коткару хезмәтләре һәм коткаручылар статусы турында» Федераль законга, 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы «Граждан оборонасы турында» Федераль законга, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законга, РФ Хөкүмәтенең 2003 елның 30 декабрендәге 794 номерлы «Гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы турында» карарына, Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларына, Биектау муниципаль районы башкарма комитетының нигезләмәсе һәм башка муниципаль хокукый актларына таяна.

3. Даими эшләүче органны булдыруның максаты булып Биектау муниципаль районының гражданнар оборонасы бурычларын хәл итүгә, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән саклауга әзерлеген гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыруны да кертеп тәэмин итү тора.

4. Даими эшләүче орган Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты составында төзелә.

5. Даими эшләүче орган үз эшчәнлеген федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләре буенча оешмалар белән үзара хезмәттәшлектә гамәлгә ашыра.

6. Даими эшләүче органны финанс белән тәэмин итү Биектау муниципаль районы башкарма комитеты чаралары исәбеннән гамәлгә ашырыла.

7. Әлеге Нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр Биектау муниципаль районы башлыгы карары белән раслана.

## II. Төп бурычлар

1. Даими эшләүче органның төп бурычлары түбәндәгеләр:

а) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;

б) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актларын үтәлешен оештыру;

в) Татарстан Республикасының гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасының территориаль ярдәмче системасының территориаль звеносы эшләвен һәм үсешен тәэмин итү;

г) Биектау муниципаль районының үз территориясе чикләрендә гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен кисәтүдә һәм юкка чыгаруда катнашуын тәэмин итү;

д) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, аларны үткәрүне контрольдә тоту;

е) гражданнар оборонасы буенча чаралар үткәрү өчен билгеләнгән, шулай ук табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләр нәтиҗәләрен бетергәндә, шул исәптән су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин иткәндә, идарә органнарын, көчләрне һәм чараларны булдыру һәм аларның әзерлеген тәэмин итү;

ё) Биектау муниципаль районының гражданнар оборонасы гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнары һәм оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

ж) Биектау муниципаль районы чикләрендә янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү;

з) Биектау муниципаль районы территориясендә су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү, аларның гомерен һәм сәламәтлеген саклау чараларын оештыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

и) Биектау муниципаль районы территориясендә авария-коткару хезмәтләрен һәм (яисә) авария-коткару формированиеләрен төзүне, аларны карап тотуны һәм эшчәнлеген оештыруны тәэмин итү;

й) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы законнарын, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актларын гамәлгә

ашыруга юнәлдерелгән башка бурычлар.

## III. Төп функцияләре

1. Даими эшләүче орган үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге төп функцияләрне башкара:

1) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә бердәм дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшләү һәм кертү;

2) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә норматив хокукый актлар әзерләүдә катнашу (билгеләнгән тәртиптә муниципаль хокукый актлар проектларын әзерләүне һәм гамәлгә кертүне дә кертеп);

3) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә Биектау муниципаль районы башкарма комитетының хокукый актларын федераль законнар, Татарстан Республикасы законнары, Биектау муниципаль районы уставы таләпләре белән үз вакытында яраклаштыруны тәэмин итү;

4) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә муниципаль максатчан программалар эшләү һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

5) гражданнар оборонасы мәсьәләләре буенча төп чараларны, гадәттән тыш хәлләрне кисәтүне һәм бетерүне, аларның үтәлешен контрольдә тотуны гамәлгә ашыруда катнашуны күздә тоткан еллык һәм перспективалы планнарны эшләү һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

6) гражданнар оборонасы буенча чараларны оештыруны һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү, күрсәтелгән чараларны үткәрүне контрольдә тоту;

7) халыкны һәм территорияне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән яклау чараларын оештыруны һәм гамәлгә ашыруны тәэмин итү, күрсәтелгән чараларны үткәрүне контрольдә тоту;

8) гражданнар оборонасы көчләрен, чараларын, объектларын төзү һәм аларны әзерлектә тотуны тәэмин итү;

9) идарә органнарының, көчләренең һәм чараларының гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә әзерлеген анализлау һәм бәяләү;

10) гражданнар оборонасы объектларына гомуми ихтыяҗны билгеләү, гамәлдәге һәм төзелә торган гражданнар оборонасы объектларын исәпкә алуны алып бару;

11) тыныч вакытта Биектау муниципаль районы территориясендә гражданнар оборонасы объектларын булдыруны тәэмин итү, аларны файдалануга даими әзерлектә тоту, шул исәптән контроль чараларны гамәлгә ашыру;

12) территорияләрне гражданнар оборонасы буенча төркемнәргә кертү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнашу, аларны Россия Федерациясе субъектының башкарма хакимияте органнарына кертү;

13) гражданнар оборонасы максатларында Биектау муниципаль районының матди-техник, азык-төлек, медицина һәм башка чаралары запасларын булдыруны һәм

тотуны тәэмин итү;

14) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү өчен, матди һәм финанс ресурслары резервларын туплауны оештыру һәм туплауны, аларны саклау һәм тулыландыруны контрольдә тоту;

15) югары хәвеф-хәтәр объектларына, халыкның тормышын тәэмин итү системаларына иминият фондын булдыруны һәм саклауны тәэмин итү;

16) гражданнар оборонасы буенча чаралар турында, хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә барлыкка килә торган куркынычлар турында, гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы турында, шул исәптән халыкка экстрен хәбәр итүнең комплекслы системасын кулланып, халыкка вакытында хәбәр итүне һәм мәгълүмат җиткерүне оештыру һәм тәэмин итү;

17) гадәттән тыш хәлләр барлыкка килү яисә килеп чыгу куркынычы турында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына хәбәр итү;

18) гадәттән тыш хәлләр турында халыкка хәбәр итүнең һәм мәгълүмат җиткерүнең муниципаль системаларын төзүне оештыру, аларны даими әзерлектә тотуны тәэмин итү;

19) Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан халыкка хәбәр итү системаларыннан, гражданнар оборонасы объектларыннан файдалануга даими әзерлектә тотуны тәэмин итү;

20) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә билгеләнгән тәртиптә мәгълүмат җыюны һәм алмашуны оештыру һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

21) халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына кешеләр күпләп җыела торган урыннарда халыкка хәбәр итү һәм (яисә) мәгълүмат җиткерү өчен участоклар бирү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары продукциясен тарату өчен булган техник җайланмалар бирү, халыкка гадәттән тыш хәлләр турында үз вакытында хәбәр итү һәм халыкны гадәттән тыш хәлләрдән саклау өлкәсендә халыкны әзерләү максатларында эфир вакытын бүлеп бирүдә ярдәм күрсәтү;

22) Биектау муниципаль районы башлыгына җирле дәрәҗәдә җавап бирү кертү турындагы тәкъдимнәрне тапшыру;

23) гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү буенча бердәм дәүләт системасы идарәсе органнпарына һәм көчләренә югары әзерлек режимын, гадәттән тыш хәл режимын кертү турында тәкъдимнәр тапшыру;

24) «112» бердәм номеры буенча ашыгыч оператив хезмәтләрне чакыртуны тәэмин итү системасын булдыруда, эксплуатацияләүдә һәм үстерүдә катнашуны тәэмин итү;

25) эвакуацияне планлаштыруны, әзерләүне һәм уздыруны (эвакуация комиссияләрен төзүне, аларның шәхси составын әзерләүне дә кертеп) оештыру;

26) эвакуацияләнгән халыкны урнаштыру һәм аның тормыш-көнкүрешен тәэмин итү, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне саклау өчен районнарны әзерләү;

27) Биектау муниципаль районы чикләре чикләрендә сугыш чорында оешмаларның тотрыклы эшләвенә ярдәм итү буенча беренче чираттагы чараларны планлаштыру һәм үткәрүне оештыру;

28) гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның, предприятиеләрнең, учреждениеләрнең тотрыклы эшләвенә ярдәм күрсәтүгә юнәлдерелгән чаралар

үткәрүне оештыру;

29) авария-коткару хезмәтләрен һәм (яисә) авария-коткару формированиеләрен төзүне, карап тотуны һәм аларның эшчәнлеген оештыру, аларның эшчәнлеген координацияләү;

30) авария-коткару һәм башка кичектергесез эшләрне оештыруны һәм уздыруны, үз көчләре һәм чаралары җитмәгәндә Россия Федерациясе субъектларының башкарма хакимияте органнарына ярдәм итү өчен билгеләнгән тәртиптә мөрәҗәгать итү;

31) хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә халыкның шушы гамәлләре нәтиҗәсендә зыян күрүчене беренче чиратта тәэмин итүне оештыруда катнашу;

32) су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү чараларын гамәлгә ашыруны оештыру һәм тәэмин итү, суларның тискәре йогынтысын булдырмау һәм аның нәтиҗәләрен бетерү чараларын гамәлгә ашыру, муниципаль берәмлек милкендәге су объектларын саклау чараларын гамәлгә ашыру;

33) муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларыннан шәхси һәм көнкүреш ихтыяҗлары өчен файдалану кагыйдәләрен эшләүдә катнашу;

34) гражданнарга Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан гомуми файдаланудагы су объектларында судан файдалануның чикләүләре турында мәгълүмат бирүне тәэмин итү;

35) гражданнар оборонасы өлкәсендә хәрби хәрәкәтләр алып барганда яисә шушы гамәлләр нәтиҗәсендә барлыкка килә торган хәтәрләрдән саклану ысулларына, шулай ук гадәттән тыш хәлләрдә саклану һәм гамәлләр ысулларына халыкны әзерләүне һәм укытуны оештыру;

36) Биектау муниципаль районы даими эшләүче органның, хезмәтләренең һәм формированиеләренең шәхси составын укытуны оештыру, шул исәптән Биектау муниципаль районы территориясендә урнашкан оешмаларның хезмәткәрләрен, формированиеләренең һәм хезмәтләренең шәхси составын укытуны оештыру һәм контрольдә тоту;

37) Биектау муниципаль районы оешмаларының һәм хезмәтләренең шәхси составы эшләүче халыкны, вазыйфаи затларны һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләрен укытуның якынча программаларын эшләүдә катнашу;

38) гражданнар оборонасы буенча өйрәнүләр һәм күнегүләр үткәрүне оештыру;

39) гражданнар оборонасы буенча уку-консультация пунктларын төзүне, җиһазлауны тәэмин итү, аларның эшчәнлеген оештыру, шулай ук тиешле лицензиясе булган өстәмә һөнәри белем бирү мәгариф учреждениеләрендә вазыйфаи затларның һәм гражданнар оборонасы хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрүне тәэмин итү;

40) гражданнар оборонасы өлкәсендә белемнәрне пропагандалауны оештыру һәм гамәлгә ашыруда катнашу;

41) әйләнә-тирә мохитнең торышын өйрәнүне һәм гадәттән тыш хәлләрне фаразлауны оештыру;

42) гадәттән тыш хәлләр турында статистик хисап алып баруны оештыру, аварияләр һәм һәлакәтләр сәбәпләрен тикшерүдә катнашу;

43) Россия Федерациясе, Татарстан Республикасы, Биектау муниципаль районының муниципаль хокукый актлары нигезендә куелган бурычларны үтәүгә бәйле башка функцияләр.

## IV. Даими эшләүче орган вәкаләтләре

1. Даими эшләүче орган түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

а) җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү һәм су объектларында кешеләрнең куркынычсызлыгын тәэмин итү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияли;

б) кул астындагы органнарның һәм бүлекчәләрнең эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аны камилләштерү буенча тәкъдимнәр эшли, билгеләнгән бурычларның һәм функцияләрнең үтәлешен контрольдә тота;

в) кул астындагы органнар һәм бүлекчәләр эшчәнлеген хокукый һәм мәгълүмати тәэмин итүне гамәлгә ашыра;

г) халыкны һәм территорияне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны хәл итүгә вәкаләтле федераль башкарма хакимият органының территориаль органы белән үз дәрәҗәсендә булмаган гадәттән тыш хәлләр һәм янгыннар турында массакүләм мәгълүмат чараларына җибәрелә торган мәгълүматны килештерә;

д) дөреслеге шик тудырган бирелгән мәгълүматны территориаль мониторинг үзәкләрендә билгеләнгән тәртиптә 2 сәгать эчендә яңадан тикшерә;

е) гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның тикшерүләрен билгеләнгән тәртиптә үткәрә, комплекслы һәм максатчан тикшерүләрдә катнаша;

ж) оешмалар җитәкчеләренә гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау мәсьәләләрен җайга сала торган Россия Федерациясе законнарын һәм муниципаль хокукый актларны тиешенчә үтәү буенча тәкъдимнәр һәм рекомендацияләр җибәрә;

з) йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүматны һәм белешмәләрне соратып ала;

и) гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләрне кисәтү һәм бетерү мәсьәләләре буенча тикшеренүләр үткәрү, экспертиза һәм бәяләмәләр әзерләү өчен экспертлар җәлеп итә;

к) кирәк булганда даими эшләүче орган каршында эксперт советы төзи;

л) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендәге бурычларны һәм функцияләрне гамәлгә ашырганда дәүләт хакимиятенең федераль органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, оешмалар белән үзара эшчәнлекне гамәлгә ашыра;

м) компетенциясе чикләрендә җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән үзара хезмәттәшлекне гамәлгә ашыра;

н) гражданнарның, оешмаларның, дәүләт хакимияте органнарының һәм җирле үзидарә органнарының мөрәҗәгатьләрен карый, ачыкланган проблемаларны бетерү чараларын күрә;

о) тематик киңәшмәләр, семинарлар, конференцияләр оештыра һәм үткәрә;

п) билгеләнгән бурычларны һәм функцияләрне башкаруга бәйле башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

## V. Даими эшләүче орган белән җитәкчелек итү

1. Даими эшләүче орган эшенә гомуми җитәкчелекне Биектау муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесе башкара.

2. Эшкә турыдан-туры җитәкчелек итүне гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә даими эшләүче орган җитәкчесе гамәлгә ашыра.

Даими эшләүче орган җитәкчесе:

а) даими эшләүче органның эшен оештыра;

б) хезмәткәрләрне эшкә кабул итә, күчерә һәм эштән чыгара;

в) бүлекнең һәм авария-коткару хезмәтләренең һәм формированиеләрнең шәхси составын формалаштыруны, аларның һөнәри әзерлеген, законлылыкны һәм дисциплинаны үтәвен тәэмин итә;

г) кул астындагы органнарны һәм бүлекчәләрне төзү, үзгәртеп оештыру һәм бетерү буенча тәкъдимнәр әзерләүдә катнаша;

д) билгеләнгән тәртиптә матди-финанс тәэмин итүне планлаштыруда, бүлеп бирелгән финанс чараларын һәм матди ресурсларны бүлүдә катнаша;

е) дәүләт, хезмәт һәм закон тарафыннан саклана торган башка серләрнең саклanышы таләпләрен үтәүне, конфиденциаль характердагы белешмәләрне таратмау, хезмәтне саклау, янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләренең үтәлешен тәэмин итә;

ж) гадәттән тыш хәлләр һәм янгыннар турында массакүләм мәгълүмат чаралары аша халыкка мәгълүмат җиткерүне оештыру өчен җаваплы булып тора, телевизион тапшырулар һәм радиотапшырулар программаларын тарату өчен элемтә челтәрләре буенча мәгълүмат һәм хәбәр итү сигналларын тапшыруга рөхсәт бирә;

з) федераль дәүләт хакимияте органнары һәм аларның территориаль органнары, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары, оешмалар, гражданнар белән үзара хезмәттәшлекне оештыра;

и) билгеләнгән тәртиптә дәүләт хакимияте органнарында һәм җирле үзидарә органнарында даими эшләүче орган тапшыра, җәмәгатьчелек, массакүләм мәгълүмат чаралары белән эшләгәндә вәкиллек функцияләрен үти;

к) ведомствоара комиссияләр эшендә катнаша;

л) үзенә бирелгән хокук чикләрендә бүләкләү һәм дисциплинар җәза куллана;

м) гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш хәлләрдән яклау өлкәсендә алдынгы эш тәҗрибәсен гомумиләштерүне һәм таратуны оештыра;

н) гражданнар оборонасы һәм халыкны яклау чараларын оештыру һәм уздыру өчен шәхси җаваплылык тота;

о) даими эшләүче органның эше турында билгеләнгән тәртиптә хисап әзерләүне һәм тапшыруны гамәлгә ашыра.